КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 март г.Казань № 283

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән һәм алар хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтыла торган мәшгуль булмаган гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 ел, 26 гыйнвар, 58 нче карары гамәлен туктатып тору турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты кысаларында аерым категориядәге гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру өчен коммерциягә карамаган оешмаларга федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү турында» 2021 ел, 13 март, 369 нчы һәм «2024 елга кадәрге чорга аерым категориядәге гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 27 май, 800 нче карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республика-

сында Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән һәм алар хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтыла торган мәшгуль булмаган гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 ел, 26 гыйнвар, 58 нче карары гамәлен 2024 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин